**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы**
**Келәнче авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**2018 ел, 24 сентябрь** **№ 82**

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Келәнче авыл җирлеге Советының 2013 елның 17 декабрендәге “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы “Келәнче авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында” 87 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына үзгәрешләр кертүгә бәйле рәвештә, гамәлдәге законнар нормаларына тәңгәлләштерү максатларында Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Келәнче авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Келәнче авыл җирлеге Советының 2013 елның 17 декабрендәге 87 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы “Келәнче авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә түбәндәге узгәрешләр кертергә:

1.1. 1нче статьяның унынчы абзацын “капиталь ремонт” сүзләреннән соң “, сүтү” сүзе белән тулыландырырга;

1.2. 26нчы статьяда:

а) 1нче пунктның икенче абзацның түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Шәхси торак төзелеше объекты, бакча йорты төзегәндә, реконструкцияләгәндә проект документларын әзерләүне гамәлгә ашыру таләп ителми. Төзүче үз инициативасы буенча индивидуаль торак төзелеше объектына, бакча йортына карата проект документларын әзерләүне тәэмин итәргә хокуклы.”;

б) 8нче пунктның 2 пунктчасын түбәндәге редациядә бәян итәргә:

“2) җир кишәрлеген шәһәр төзелеше планында күрсәтелгән мәгълүмат нигезендә планлаштыру схемасы;”;

в) 8нче пунктның 7 пунктчасында “яки демонтажлау” һәм “яки демонтаж” сүзләрен төшереп калдырырга;

г) 8нче пунктның 10 пунктчасыннда “капиталь ремонт” сүзләреннән соң “, сүтү” сүзе белән тулыландырырга.

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендлар аша халыкка белдерергә:

- ТР, Кама Тамагы районы,  Keләнче авылы, Г.Тукай ур.,35нче йорт;

- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Бәки авылы, Фрунзе ур.,

шулай ук мәгълүмат-телекоммуникация «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы районы рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуын үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Кама Тамагы муниципаль районы
Keләнче авыл җирлеге Башлыгы,
Татарстан Республикасы
Кама Тамагы муниципаль районы
Keләнче авыл җирлеге Советы рәисе Д.А.Кадыров.